МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 28/о

ПРИКАЗ "19" 02 2018 БОЕРЫК

«Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе турында нигезләмә раслау турында» 2016 елның 22 мартындагы 54/о номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссияләр турында» 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы указына туры китереп боерык бирәм:

1. «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының Татарстан

Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе турында нигезләмә раслау турында» 2016 елның 22 мартындагы 54/о номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясе турында нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Нигезләмәнең 2.2 пунктының «а» пунктчасында, 3.1 пунктының «б» пунктчасында, 3.2 пунктында, 3.5 пунктының «б» пунктчасында, 3.31 пунктында «кадрлар сәясәте бүлеге» сүзләрен «дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

Нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле 3.4.3 пунктын өстәргә:

«3.4.3. Әлеге Нигезләмәнең 3.2, 3.4, 3.4.1 пунктларында каралган дәлилле бәяләмәләрдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдә яисә хәбәрләмәләрдә бәян ителгән мәгълүмат;

б) гарызнамәләр нигезендә дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм мәнфәгатьле оешмалардан алынган мәгълүмат;

в) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне яисә хәбәрләмәләрне беренчел карау нәтиҗәләре буенча дәлилле нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.13, 3.15.1, 3.18 пунктлары нигезендә карарларның берсен яисә башка төрле карарны кабул итү өчен киңәшләр.

2. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю.Латыйповага дәүләт теркәвенә алу өчен әлеге боерыкның билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы җитәкчесе Г.С.Миңнехановага әлеге боерыкның “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр И.Ә.Фәйзуллин

МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА · ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫК МИНИСТРЛЫГЫ
ОТДЕЛ ОРГАНИЗАЦИОННО-ПРОТОКОЛЬНОЙ РАБОТЫ, КОНТРОЛЯ И ДЕЛОПРОИЗВОДСТВА